ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.05.2017 Казан ш. № 7-3/т

Татарстан Республикасының Яшел Үзән муниципаль районы, «Свияжски авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан причалны бирү буенча «Татфлот» суднолар йөртү компаниясе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә чик дәрәҗәдә максималь тариф билгеләү хакында

«Табигый монополияләр турында» 1995 елның 17 августындагы 147-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Транспорт терминалларында, портларда, аэропортларда табигый монополияләр субъектлары хезмәтләренә һәм эчке су юллары инфраструктурасыннан файдалану хезмәтләренә бәяләрне (тарифларны, җыемнарны) дәүләти җайга салу турында» 2008 елның 23 апрелендәге 293 номерлы һәм «Россия Федерациясе субъектларының тарифларны дәүләти җайга салу өлкәсендәге башкарма хакимияте органнарының табигый монополияләр субъектларының эшчәнлеген дәүләти җайга салуда һәм аңа контрольлекне гамәлгә ашыруда катнашуы турында» 2008 елның 10 декабрендәге 950 номерлы карарлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Яшел Үзән муниципаль районы, «Свияжски авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан причалны бирү буенча «Татфлот» суднолар йөртү компаниясе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә, шушы карар кушымтасына туры китереп, чик дәрәҗәдә максималь тариф билгеләргә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
05.05.2017 ел № 7-3/т карарына
кушымта

Татарстан Республикасының Яшел Үзән муниципаль районы, «Свияжски авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан причалны бирү буенча «Татфлот» суднолар йөртү компаниясе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә чик дәрәҗәдә максималь тариф

| № п/п | Хезмәт төре | Үлчәү берәмлеге | Тариф |
|---|---|---|---|
| 1. | Йөк операцияләрен башкармыйча гына суднолар туктатып тору өчен причал бирү | судноның 1 метрлы габарит озынлыгы өчен сәгатенә/сум | 20 |

Искәрмә:

1. Татарстан Республикасының Яшел Үзән муниципаль районы, «Свияжски авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан причалны бирү буенча «Татфлот» суднолар йөртү компаниясе» акционерлык җәмгыяте (алга таба – Җәмгыять) тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган хезмәтләргә чик дәрәҗәдә максималь тариф куллану.

2. Клиентлар белән шартнамәләр төзегәндә Җәмгыять чик дәрәҗәдә максималь күрсәткеч дәрәҗәсендә яисә аннан түбәнрәк дәрәҗәдә тариф кулланырга хокуклы.

3. Чик дәрәҗәдә максималь тариф өстәлгән бәясенә салымны исәпкә алмыйча күрсәтелде.

4. Татарстан Республикасының Яшел Үзән муниципаль районы, «Свияжски авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан причалны судноны туктатып тору өчен йөк операцияләрен башкармыйча бирү буенча хезмәтләрнең бәясе шушы карарга кушымта нигезендә, тарифны причалда басып тору вакытына һәм судноның габарит озынлыгына тапкырлау юлы белән ачыклана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге